**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4449**
**08.09.2020**

2021-2036 еллар чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү проекты буенча җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү схемаларын эшләү һәм раслау тәртибенә карата таләпләрнең 20, 23 пунктлары, Шәһәр Советының 2013 елның 21 февралендәге 23/9 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты буенча җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2021-2036 еллар чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү проекты буенча җәмәгать тыңлауларын 2020 елның 17 сентябренә билгеләргә.

Үткәрү урыны: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 400 зал. Тыңлауларның башлану вакыты: 14 сәгать 00 минут.

2. 2021-2036 еллар чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия составын кушымтада каралганча расларга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 8 сентябрендәге
4449 номерлы карарына
кушымта

2021-2036 еллар чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең актуальләштерелгән җылылык белән тәэмин итү схемасының эшләп бетерелгән проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Ф.Ш. | Башкарма комитет Җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2. | Зуев И.С. | Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| 3. | Хәбибуллин Ф.Ф. | Башкарма комитет шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең энергетика бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 4. | Әхмәтҗанов Л. И. | Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы |
| 5. | Гаврилов В.А. | «КАМАЗ-Энерго» ҖЧҖнең генераль директоры (килешү буенча) |
| 6. | Галиәхмәтов Р.М. | «Татэнерго» АҖның стратегик үсеш буенча генераль директор урынбасары (килешү буенча) |
| 7. | Галимов И.Н. | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы |
| 8. | Зәйнуллин А.З. | Шәһәр Советы депутаты, «Татэнерго» АҖ филиалы – Яр Чаллы җылылык челтәрләре директоры (килешү буенча) |
| 9. | Исхаков И.З. | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 10. | Кислов А.И. | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы |
| 11. | Королев А. Г. | «Татэнерго» АҖның стратегик үсеш һәм инвестицияләрне тормышка ашыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 12. | Поленов А.Л. | «Энерготехаудит» ИҮ» ҖЧҖнең генераль директоры (килешү буенча) |
| 13. | Сафиуллин Ф.Ф. | «КамгэсЗЯБ» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) |
| 14. | Ситдыйков С.Ә. | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 15. | Хаҗиев Ә.М. | «Татэнерго» АҖ филиалы – «Яр Чаллы Теплоэлектроцентрале» директоры (килешү буенча) |
| 16. | Харисов В.Х. | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева